Хөсәинова, Д. Хәрби-язучы / Д. Хөсәинова; М. Сафин [б-н әңгәмә] // Көмеш кыңгырау. – 2025. – №6 (15 февраль). – Б. 4.



# Хәрби-язучы

**Күренекле шәхес Мансур Сафин, лицеебызда кунакта булып, безгә кызыклы әдәбият дәресе үткәрде. Дәрестән соң, без Мансур абыйдан интервью алдык.**

*Мансур Габдулла улы Сафин – татар язучысы, Шәйхи Маннур исемендәге премия иясе, Эдуард Касыймов һәм Егор Уткин премияләре лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге, Россия һәм Татарстан журналистлар берлекләре әгъзасы.*

**– Мансур абый, әйтегез әле, Сез кечкенәдән үк язучы, тарихчы булырга теләдегезме?**

– Мин балачактан ук укырга яраттым, шигырьләр яздым. Мамадышның район китапханәсендәге барлык китапларны укып бетергәнмендер, дип уйлыйм. Мәктәптә стенгазета редакторы идем. Беренче шигырьләремне 5нче сыйныфта яздым. Язучы булырмын, дип тә уйламаган идем, башта хәрби һөнәрен сайладым. Инженерга, журналистка укып чыктым. Әмма язучы-шагыйрь булырга язган, күрәсең, янә шуңа әйләнеп кайттым.

**– Сезнең ничә китабыгыз бар?**

– Күп алар. Йөздән артык, әмма күбесенең тиражы бәләкәй, 50-100 данә.

**– Сез бик күп тәрҗемә итәсез. Кайсы авторны тәрҗемә итү аеруча ошады?**

– Мин, гомумән, үземә ошаган авторларны гына тәрҗемә итәм. Әйтик, шагыйрь Велимир Хлебниковның теле бик кызыклы. Аның белән биографияләребез дә охшаган, бәлки, шуңа да кызык һәм якын булып тоеладыр.

**– Татар телен саклап калу өчен, бүген ниләр эшләргә кирәк?**

– Туган телебездә кызыклы чаралар күбрәк үткәрергә кирәк. Шулай ук түрәләр тарафыннан да бу мәсьәлә күз уңында тотылсын иде. Шул ук трамвай-автобусларда тукталыш исемнәре, атамалар, элмә такталар ике телдә булсын иде. Шулчак татар теле һәрвакыт күз алдында булыр, ешрак ишетелер, истә калыр.

***Балалар татар теле һәм әдәбиятының матурлыгын, байлыгын күрергә тиеш.***

**– Укучыларга теләкләрегез?**

– «4-5»ле билгеләренә генә укыгыз. Мәктәп программасын үзләштереп барыгыз. Яхшы кеше булып үсегез. Туган телебезне белегез һәм хөрмәт итегез, балалар.

**Диләрә ХӨСӘИНОВА,**
*Яр Чаллы шәһәре,*
*Гали Акыш исемендәге 84нче лицей-интернат. Автор фотосы.*